# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

унберенче утырыш
## КАРАРЫ

30 нчы июнь 2021 ел **№ 63** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 4 апрелендәге 199 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» карары( 26.05.2014 № 210, 15.11.2016 № 67, 20.04.2017 № 84, 19.07.2017 № 90, 12.04.2018 № 210, № 127, 24.08.2018 № 141, 13.12.2018 № 160, 20.01.2020 № 224, 30.07.2020 № 246, 03.09.2020 № 248 карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (алга таба текст буенча-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 22 өлешендә «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2) 7 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

3) 16 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр» сүзләрен өстәргә.

4) 26 статьяның 10 өлешендәге 2 пунктында «хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга.

5) 28 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәт стажын раслый торган төп документлар булып билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр тора.»;

б) 4 өлештә «хезмәт кенәгәсенә» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

б) 32 статьяның 4 пунктында «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру» сүзләрен өстәргә;

7) 32.1 статьяның 11 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов